ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**Приказ** **г. Казань** **Боерык**

11.02.2021 № 40-од

Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануччы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә корал, хәрби кирәк - яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 нче елның 5 нче августында кабул ителгән 545 нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 2020 елның 28 декабреннән 1209 нчы номерлы карары басылуга бәйле рәвештә карар бирәм:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануччы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Хокукый эш буенча әйдәп баручы киңәшчегә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алуны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.09.2010 ел, 729 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертү өчен регламентны җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Ю.Б. Матвеевка йөкләргә

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
2021 елның 11 нче
февраленнән 40-од номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклanучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты ( алга таба – Регламент), Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели ( алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр түбәндәгеләр: Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне үз теләкләре белән тапшырган 18 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк гражданнар(алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Татарстан” тукталышына кадәр :
автобуслар № 1, 31, 53, 54, 6, 71;
троллейбуслар №3, 5;
«Ахтямов» тукталышына кадәр :
автобуслар № 23,5, 56, 68, 71, 72.
Керү шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Комитетның белешмә телефоны: 211-66-94.

1.3.3. Комитетның мәгълүмати-телекомммуникатив «Интернет» челтәрендә, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Реестры» дәүләт

мәгълүмати системасына керә торган, рәсми сайт адресы http://www.ojm. tatarstan .ru, электрон почта адресы: ojm@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) мәгълүмати-телекомммуникатив «Интернет» челтәре аша:

-Комитетның рәсми сайтында http://www.ojm.tatar.ru;

-Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

-Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

- Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/).

2) Комитетка телдән мөрәҗәгать итеп ((843)211-66-94);

3) Комитетка язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда ojm@tatar.ru рәсми электрон почтага җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

4) «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенә һәм күп функцияле үзәкнең (алга таба - КФҮ) читтән торып эш урынына мөрәҗәгать иткәндә( шәхси).

1.3.5. Комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, электрон почтасы,КФҮ нең урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры»нда урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

корал - тере яки башка әйберне юкка чыгару, сигнал бирү өчен конструктив билгеләнгән җайланмалар һәм предметлар;

шартлаткыч җайланмалар астында функциясе ягыннан шартлаткыч матдәне һәм шартлату җайланмаларын (запал, шартлаткыч, детонатор һ. б.) берләштерүче сәнәгать яки кулдан ясалган эшләнмәләрне аңларга кирәк.

шартлаткыч матдәләр астында, тышкы йогынтысының билгеле бер төрләрендә җылылык һәм газ бүлеп чыгара торган бик тиз таралучы химик әйләнешкә сәләтле матдәләрне аңларга кирәк.;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында»гы 1376 нчы карары белән

расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр округы яки яки шәһәрдә (авыл җирлегендә) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

техник хата - дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматларның(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документларга тәңгәл килмәвенә китергән хата(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата);

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгать аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.1 п.). Гаризаларның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклаучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә корал, хәрби кирәк - яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында” 1995 нче елның 5 нче августында кабул ителгән 545 нче номерлы карары (алга таба - ТР МК 05.08.1995 елдан 545 нче номерлы карары) |
| 2.2. Башкарма хакимият | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт | ТР МК 05.08.1995 |

| | | |
|---|---|---|
| органының исеме | комитеты ( алга таба – Комитет) | елдан 545 нче номерлы карарының 5 нче пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклանучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләмәү) турында карар | ТР МК 05.08.1995 елдан 545 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклանучы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча эшне оештыру турындагы нигезләмәнең 6 нчы пункты (алга таба –Нигезләмә) |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт | Акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турындагы карарны кабул итү, документлар гариза бирүче (аның | Нигезләмәнең 6, 14, 15 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | вәкаләтле вәкиле) тарафыннан документлар КФҮгә тапшырган көннән алып, 61 эш көне эчендә кабул ителә.<br>Мөрәҗәгать итүчегә акчалата хакны түләү турында карар кабул ителгәннән соң, акча 30 эш көне эчендә түләнә.<br>Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска) акчалата түләү (түләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр җибәрү, аны кабул иткән көннән со,ң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе. | Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча гариза;<br>шәхесне раслаучы документ күчермәләре;<br>Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча идарәсе яки Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары тарафыннан бирелә торган коралны, хәрби кирәк-яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне тапшыру турында квитанция;<br>акчалата түләү күчерелергә тиешле Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмасы учреждениесендә ачылган счет реквизитлары.<br>вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәләре (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил килсә).<br>Гариза һәм теркәлеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь иядә КФҮ аша, КФҮнең ерактан торып эш урыны аша тапшырыла. | Нигезләмәнең 4 нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар  карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә;аларны бирү тәртибе. | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында салым органында (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә) исәпкә кую турында белешмәләр соратып алына.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны һәм аларны тапшыру тәртибе, әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша алырга тиеш булган документларны тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүчедән  түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирдертү;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү кертүне раслаучы документларны һәм мәгълүматны бирдертү;<br>№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирдертү. | Нигезләмәнең 4 нче пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән зат тарафыннан документларны тапшыру;<br>2) әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә булган документларны тапшырмау;<br>3) документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган чистартулар, өстәмә язулар, дөрес язылмаган сүзләр һәм төзәтмәләр булу. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.<br>Агымдагы финанс елында акчалата түләү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларының җитәрлек булмавы, акчалата хакны түләүдән баш тарту өчен нигез булып тора | Нигезләмәнең 13 нче пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| белешмәләр | | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, соратып алуны теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза һәм әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар алынганнан соң, бер эш көне эчендә, КФҮдән | Нигезләмәнең 7 нче пункты |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү | Дәүләт хезмәтен күрсәтү, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен | ст.15 Федерального закона от 24 ноября |

| | | |
|---|---|---|
| залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган Комитетның бинасында һәм бүлмәләрендә тормышка ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен җайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляскадан һәм этләрдән файдалана торганнарга, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;<br>Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның чикләүләрен исәпкә алып, биналарга, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүгә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматларны җайлы итеп урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм язма мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктала шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү; | 1995 года № 181-ФЗ «О социальной защите инвалидов в Российской Федерации», постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 02.11.2010 № 880 «Об утверждении Порядка разработки и утверждения административных регламентов предоставления государственных услуг исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан и о внесении изменений в отдельные постановления Кабинета Министров Республики Татарстан» |

| | | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатучы этнең махсус укытуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә һәм махсус укытуны раслый торган документ булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә, озатучы этне кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт алырга комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, үзгәртеп корылган, модернизация узган объектларга карата кулланыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать транспортына үтемлелек зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарны инвалидлар өчен уңайлы итү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплекслы запрос ) | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>- мөрәҗәгать итүченең Комитет белгечләре белән үзара бәйләнеше булмау;<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, КФҮнең ерак эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәткәндә консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирү эшен КФҮ белгече башкара.<br>Гариза бирүче КФҮгә, КФҮнең ерактан торып эш урынына гаризаны һәм документларны тапшырганда, аларны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасында хезмәттәшлек килешү нигезендә, ә КФҮ һәм мөрәҗәгать итүчеләр арасында -КФҮ эше Регламенты белән җайга салына.<br>Экстерриториаль принцип буенча яки комплекслы соратып алу составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең | Консультация телефон аша шәхси яки электрон хәбәр формасында электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша) http://ojm.tatarstan.ru) бирелергә мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | КФҮ аша, КФҮнең ераклашкан эш урыны аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм документларны биргәндә, консультация, документлар кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында хәбәр итүне КФҮ хезмәткәре, КФҮнең ерактагы эш урыны хезмәткәре башкара. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы.

3. .1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;
КФҮдән алынган гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;
акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карар кабул итү;
акчалата хакны билгеләү турында яки түләүдән баш тарту турында хәбәрләр җибәрү;
акчалата хакны түләү;
техник хатаны төзәтү ( ялгыш язулар,  грамматик һәм орфографик хаталар).
3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү.
Мөрәҗәгать итүче комитетка телефон һәм (яки) электрон почта аша (e-mail: ojm@tatar.ru) мөрәҗәгать итә. (Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша) http://ojm.tatarstan.ru( дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу өчен, шул исәптән гаризаны рәсмиләштерүдә.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.
Процедураларның нәтиҗәсе: составы, бирелә торган документлар формасы һәм акчалата түләү алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.
3.3. КФҮдән алынган гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.
3.3.1. Кергән документлар пакетын теркәгәндә Комитет белгече түбәндәгеләрне башкара:
әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;
бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларда бетерүләр, өстәмә язулар, сызып алынган сүзләр һәм билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтмәләр булу).
Кисәтүләр булмаган очракта, Комитет белгече гариза бирүченең документларын кабул итә һәм терки.
Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Комитет белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен киртәләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрне аңлатып, аңа документларны кире кайтара.
Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, Комитет тарафыннан КФҮдән документлар алынганнан соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.
Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.
3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга ведомствоара запрос

формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Комитет белгече ведомствоара электрон багланышлар системасы аша салым органында исәпкә кую турында Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән электрон формада соратып ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында җибәрелгән ведомствоара запрос.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгечләре, ведомствоара электрон багланышлар системасы аша кергән запрослар нигезендә, законнар белән билгеләнгән срокта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: сорауларга җавап бирү нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яки соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карар кабул итү.

3.5.1. Комитет белгече акчалата хакны алу өчен документлар пакетын формалаштыра һәм акчалата түләү өчен нигезләрнең булуы яки булмавы турында карарлар чыгару өчен Комитет каршында махсус төзелгән комиссиягә (алга таба - Комиссия) тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм Комиссиягә карауга җибәрелгән документлар пакеты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Комиссия, әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә, мөрәҗәгать итүче биргән документлар, әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктлары, Нигезләмәнең 9 пункты нигезендә алынган белешмәләр (документлар) нигезендә акчалата түләү өчен нигезләрнең булуы яисә булмавы турында карарлар кабул итә. Түләүдән баш тарту турындагы карар, әлеге Регламентның 2.8 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән нигез булган очракта, комиссия тарафыннан кабул ителә.

Комиссия утырышлары Комиссия рәисе карары буенча, кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышы, комиссия әгъзаларының кимендә 50 проценты катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия составы, акчалата хакны түләү (түләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен тапшырыла торган документлар белән эшләү һәм кабул итү тәртибе Комитет боерыгы белән раслана.

Комиссия утырышында кабул ителгән акчалата түләү өчен нигезләрнең булуы яисә булмавы турындагы карарлар Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң 46 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата түләү өчен нигезләрнең булуы яки булмавы турында карар

3.5.3. Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Комитет хезмәткәре:

акчалата хакны түләү (түләүдән баш тарту) турында карар проектын әзерли;

түләү (түләүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

Комитет рәисенә (аның вәкаләтле вәкиленә) кул кую өчен түләү (түләүдән баш тарту) турында карар проектын (алга таба – Рәис) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, Комиссия беркетмәсен раслаганнан соң, өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җитәкчегә кул куюга юнәлдерелгән проектлар.

3.5.4. Рәис акчалата хакны билгеләү һәм түләү яки акчалата түләүдән баш тарту турындагы боерыкны раслый һәм кул куя. Кул куелган документлар Комитет белгеченә, Комитет рәисенең төп эшчәнлеге буенча приказларны теркәү журналында теркәү өчен җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, проектлар раслауга кергәннән соң, ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата хакны билгеләү һәм түләү яки акчалата түләүдән баш тарту турында расланган боерык

3.6. Акчалата хакны билгеләү турында яки түләүдән баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Комитет хезмәткәре гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында, акчалата хакны билгеләү һәм түләү яки акчалата түләүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, ун эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.7. Акчалата хакны түләү.

Акчалата түләү, Комитет тарафыннан үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан, гаризада күрсәтелгән мөрәҗәгать итүче счетына акча күчерү юлы белән, акчалата хакны билгеләү һәм түләү турындагы боерык нигезендә башкарыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, Комиссия тарафыннан акчалата түләү турында карар кабул ителгән көннән алып, 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең шәхси счетына акча күчерү, аның реквизитлары гариза бирүче тарафыннан бирелә.

3.8. Техник хатаны төзәтү.

Акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карарны яңадан рәсмиләштерү, билгеләү һәм түләү турындагы (түләүдән баш тарту турында) карарда кертелгән техник хаталарны (дөрес язмауларны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерү белән бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карарны яңадан ясау, мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак техник хаталы документ һәм әлеге Регламентка 2 нче кушымтасында тәкъдим ителгән формада язылган һәи теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Комитет хезмәткәре:

гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны терки;

билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турындагы карарны яңадан рәсмиләштерә;

Комитет рәисенә кул кую өчен билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Комитет рәисенә имзага җибәрелгән, билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.

3.8.2. Комитет рәисе акчалата хакны билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында яңадан рәсмиләштерелгән карарга  имза куя һәм мөһер белән раслый һәм аны Комитет хезмәткәренә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура имза кую өчен билгеләү һәм түләү (түләүдән баш тарту) турында карар проектын җибәргәннән соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.8.3. Комитет хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) гаризада күрсәтелгән ысул белән билгеләү һәм түләү турында яңадан рәсмиләштерелгән карар турында (түләүдән баш тарту турында) хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ,бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) билгеләү һәм түләү турында (түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү формалары һәм тәртибе

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Комитетның вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Комитет бүлекләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү формалары:

эш башкаруны алып бару;

каралган документларның нәтиҗәсе закон таләпләренә туры килүе (әлеге Регламентның);

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, аның нәтиҗәсен бирү вакытын һәм тәртибен саклау.

4.3. Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә.

Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, законнар белән каралган тәртиптә, җаваплылыкка тарттырылалар.

4.4. Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү,

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Комитетныэ ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ бүлегендә күрсәтелгән оешмаларның, ә шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Бүлек белгече, Бүлек башлыгы, Комитетның район хезмәткәрләре гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәрге тәртиптә, Комитет рәисенә шикаять кылу хокукына ия.

Комитет рәисе белән кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамьсезлегенә) шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

3)дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документларны таләп итү;

4)гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тартуның нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәргән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый

төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын һәм тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткән вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматларны таләп итү яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

5.3. Шикаять язмача, кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, Комитетның рәсми сайты (http://ojm.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru),, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәрен кулланып, КФҮнең рәсми сайтына (http://mfc16.tatarstan.ru) аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4.Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең яисә хезмәткәрнең исеме;

гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) белән килешмәгән дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, КФҮ, оешмалар, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларга карата шикаять

белдерүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдә яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять белдерелгәндә-теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1)шикаять, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килгән көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура органнарына юнәлтә.

5.11. Комитет карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аның вазыйфаи затларына, яки дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. КФҮкә мөрәҗәгать иткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны

Комитетка җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче КФҮгә дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән, бирелә торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка сораулар буенча хәбәр итә һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алырга мөмкин. (http://mfc16.tatarstan.ru).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүченең килгән көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тәкъдим ителә торган документларның формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы зат аша, КФҮдә, КФҮнең ераклашкан эш урыныа дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыра.

6.3.2. Гаризаларны кабул итүче КФҮ хезмәткәре, КФҮ эше Регламентында каралган процедураларны башкара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар КФҮ эше регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Гаризаны Комитетка җибәрү.

6.4.1. КФҮ белгече кабул ителгән һәм теркәлгән документларны КФҮ эше регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә Комитет һәм КФҮ арасында хезмәттәшлек - килешү нигезендә, ә КФҮнең мөрәҗәгать итүчеләр белән хезмәттәшлеге -КФҮ эше Регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮ эше регламентында, комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән срокларда, ләкин КФҮтә гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе булып, Комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар.

Татарстан Республикасы
территориясендә рөхсәтсез саклanучы
яки анда табылган коралны, хәрби
кирәк-яракларын, коралга патроннарны,
шартлаткыч җайланмаларны һәм
шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә
тапшырган өчен, гражданнарга акчалата
хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Форма

кемгә: Татарстан Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитетына
кемнән_______________________________________
______________________________________________,
(Ф.И.О.(соңгысы булган очракта))
Теркәлү адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________
Яшәү адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________
паспорт: серия _________ номер ______________
«_ __»__________________________________
___________________________________бирелде.

Акчалата хакны билгеләү һәм түләү турында гариза

______________________________________________________________________________
(Корал, хәрби кирәк-яраклары, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмалар
һәм шартлаткыч матдәләрнең атамасы)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(Корал, хәрби кирәк-яраклары, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмалар һәм
шартлаткыч матдәләрне алу турындагы квитанциянең номеры һәм датасы)
______________________________________________________________________________
үз теләгем белән тапшырылган корал өчен акчалата түләүне билгеләвегезне сорыйм.
Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) ____________________________________________________________________________
2) ____________________________________________________________________________
3) ____________________________________________________________________________

4) ______________________________________________________________________

5) _____________________________________________________________________.

Акчалата хакны билгеләү һәм түләү турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документ юллау юлы белән E-mail адресына:_____________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь иядә почта аша киләсе адрес буенча: ______________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү, яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), затсыз куллану, блок кую, персональ мәгълүматларны юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылуны, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, автоматлаштырылган режимда мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Минем шәхесемә караган һәм мин биргән гаризага кертелгән, шулай ук мин керткән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка бу документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләргә ия.

Телефон аша миңа тәкъдим ителгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм: _______________________.

Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, ягъни “Персональ мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга ризалыгымны бирәм.

| ____________ | _______________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гариза бирүченең ( вәкаләтле вәкиленең) имзасы) | (фамилия, исем, атасының исеме ( соңгысы-булган очракта)) |

Татарстан Республикасы
территориясендә рөхсәтсез сакланучы
яки анда табылган коралны, хәрби
кирәк-яракларын, коралга патроннарны,
шартлаткыч җайланмаларны һәм
шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә
тапшырган өчен, гражданнарга акчалата
хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты
рәисенә
_____________________________
(фамилия, исем, атасының
исеме ( соңгысы-булган
очракта))
кемнән:________________________
_
(фамилия, исем, атасының
исеме ( соңгысы-булган
очракта))

**Техник хатаны төзәтү турында гариза.**

Мин,_______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең (вәкаләтле вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)) тулысынча күрсәтелә)

___________________________________________________________________
(индексны күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)
_____________________________________________адресы буенча торучы,
___________________________________________________________________
(хезмәтнең атамасы)
дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган____________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:
__________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне документка кертүегезне сорыйм.

Киләсе документларны терким:

1. ________________________________________________________
2.________________________________________________________

3.____________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны(хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хаталар) төзүтүгә бирелгән гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, андый карарны электрон документ рәвешендә, киләсе электрон почтага: ________________________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазь иядә, почта аша, киләсе адрес буенча җибәрүегезне сорыйм:

______________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү, яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), затсыз куллану, блок кую, персональ мәгълүматларны юк итү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр кылуны, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, автоматлаштырылган режимда мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Минем шәхесемә караган һәм мин биргән гаризага кертелгән, шулай ук мин керткән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза тапшырган вакытка бу документлар гамәлдә һәм дөрес белешмәләргә ия.

Телефон аша миңа тәкъдим ителгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм: ________________________.

| ____________ | ______________________ | ______________________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (гариза бирүченең ( вәкаләтле вәкиленең) имзасы) | (фамилия, исем, атасының исеме ( соңгысы-булган очракта)) |

Татарстан Республикасы
территориясендә рөхсәтсез саклanучы
яки анда табылган коралны, хәрби
кирәк-ярақларын, коралга патроннарны,
шартлаткыч җайланмаларны һәм
шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә
тапшырган өчен, гражданнарга акчалата
хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына белешмә өчен кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәтсез саклануччы яки анда табылган коралны, хәрби кирәк-ярақларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаткыч матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен, гражданнарга акчалата хакны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Рәис | 211-66-47 | ojm@tatar.ru |
| Рәис урынбасары | 211-66-94 | Matveev.Yuriy@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 211-71-89 | Radik.Mutaharov@tatar.ru |
| Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге башлыгы | 211-68-04 | Gulnaz.Sabirova@tatar.ru |

Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларыннан файдалану, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |